# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлегенә кергән Татар Такталы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

17 декабрь 2021 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, түбәндәге сораулар буенча 16 һәм 17 декабрьдә узган гражданнар җыены беркетмәләре нигезендә:

“Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлегегенә кергән Татар Такталы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән сез килешәсезме?:

- Татар Такталы торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Татар Такталы торак пунктында юлларны кардан чистарту, грейдерлау (ягулык – майлау материаллары, МТЗ-82 тракторына запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Татар Такталы торак пунктында җәйге чорда территорияне чабу (ягулык – майлау материаллары, МТЗ-82 тракторына запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Татар Такталы торак пунктында чүплекләрне эттерү (чүп мәйданчыкларын карап тоту) (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Татар Такталы торак пунктында бәйрәмнәрне оештыру һәм үткәрү: Сабантуй, Халыкара өлкәннәр көне,Корбан бәйрәм, Яңа ел (канцелярия товарлары, бүләкләр, сувенирлар сатып алу.);

Бердәм протокол төзелде:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 193 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан катнашучылар саны 136 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 136 кеше тавыш бирде; «каршы» позициясе өчен җыенда катнашучылар тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлегенең Татар Такталы торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча кабул ителгән карарны танырга:

"Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлегегенә кергән Татар Такталы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән сез килешәсезме?:

- Татар Такталы торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Татар Такталы торак пунктында юлларны кардан чистарту, грейдерлау (ягулык – майлау материаллары, МТЗ-82 тракторына запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Татар Такталы торак пунктында җәйге чорда территорияне чабу (ягулык – майлау материаллары, МТЗ-82 тракторына запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Татар Такталы торак пунктында чүплекләрне эттерү (чүп мәйданчыкларын карап тоту) (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Татар Такталы торак пунктында бәйрәмнәрне оештыру һәм үткәрү: Авыл көне, Халыкара өлкәннәр көне, Яңа ел (канцелярия товарлары, бүләкләр, сувенирлар сатып алу.);

3. Әлеге карарны Аграмак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм http:// www. spasskiy.tatarstan.ru Спас муниципаль районы рәсми сайтының Аграмак авыл җирлеге битендә, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Спас муниципаль районы
Аграмак авыл җирлеге башлыгы: Р.Т. Галәветдинова

СОВЕТ АГРАМАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ